ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2026 Олы Кайбыч ав. № 255

16:21:130408:255 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларының тормыш эшчәнлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга туры китерү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 16:21:130408:255 кадастр номерлы, 1642 кв.м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Колаңгы авыл җирлеге, Колаңгы тимер юл станциясе поселогы, Шоссейная ур, 24 й.- «Автомобильләр ремонтлау» адресы буенча урнашкан универсаль торак зонасында (Ж-У) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча (кушымта) җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. 2026 елның 09 июнендә 11.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Колаңгы тимер юл станциясе поселогы, Шоссейная ур, 30 й. адресы буенча урнашкан иҗтимагый үзәк бинасында 16:21:130408:255 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3. 16:21:130408:255 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты материаллары белән (текст һәм график өлеш) эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин:

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет;
- Кайбыч районы, Колаңгы тимер юл станциясе поселогы, Шоссейная ур, 5 й.

3.1. 16:21:130408:255 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

- 16:21:130408:255 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 е. 28. 05. ___ 255 номерлы
карарына кушымта

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРОЕКТ**

№__________

П Р И К А З　　　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

«_____»______________, 20__

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе тәкъдимнәрен исәпкә алып, карар бирәм:

1. Хәйруллин Рөстәм Ришад улына 16:21:130408:255 кадастр номерлы, 1642 кв.м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Колаңгы авыл җирлеге, Колаңгы тимер юл станциясе поселогы, Шоссейная ур, 24 й.-«Автомобильләр ремонтлау» адресы буенча урнашкан универсаль торак зонасында (Ж-У) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә.

2. Массакүләм мәгълүмат чаралары (Р.Ж.Зәйнуллинага) белән хезмәттәшлек итү секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә (А.А.Шәйдуллинага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгару өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Территорияләрне үстерү департаменты Җитәкчесе** **А.И. Әхмәтҗанов**